# Татарстан Республикасы Азнакай район Советы
# КАРАРЫ

Азнакай шәһәре № 36-6 «24» февраль 2021ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2012 елның 28 маендагы 155-21 номерлы «Азнакай муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турында» карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын фаразланган үтәү йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча 2021 елның 04 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегия беркетмәсенең 24,25 пунктларын үтәү йөзеннән,

Азнакай район Советы карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2012 елның 28 маендагы 155-21 номерлы «Азнакай муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турында» карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 7.9 пунктның 1) пунктчасын түбәндәге эчтәлекел 5 абзац өстәргә:

«-Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр түләү буенча бурычлар (үтәлмәгән бурыч) булмавы турында белешмә.»;

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru//.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин